**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**«Староромашкинская средняя общеобразовательная школа»**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по учебно-воспитательной работе | Директор школы |
| ________ Нуртдинов Р.Г. | ________ Фахретдинова Л.Н. | ________ Р.Ш.Сабитов |
| Протокол № 1 от 26.08.2023 г. | 26.08.2023 г. | № 162 от 28.08.2023г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

по элективному курсу

для обучающихся 11 класса

“СЛОВО - ЗЕРКАЛО ДУШИ ”

с. Старое Ромашкино, 2023/2024 учебный год

**Аңлатма язу.**

Бүгенге көндә илнең киләчәге булачак яшь буынны тәрбияләүгә игътибар арта бара. Укыту-тәрбия системасын яңарту максатыннан мөһим чаралар күрелә,Федераль дәүләт белем бирү стандартлары тормышка ашырыла, мөһим юнәлешләрнең берсе - профильле урта мәктәп булдыру өстендә эш алып барыла. Профильләштерүнең төп максаты булып - һәр баланың кызыксынуын, сәләтен, һәвәслеген мөмкин кадәр иртәрәк ачыклау, аңа үзен табарга, аңларга булышу, киләчәктә һөнәри эшчәнлек өчен юнәлеш бирү, яшь буынны мөстәкыйль тормышка әзерләү тора.

Балага киләчәктә күңеленә ошаган һөнәрне сайлау өчен төрле профиль юнәлешләре тәкъдим итү - мәктәпнең асыл максаты. Бүгенге яшьләр арасында филология фәннәре белән бәйле белгечлекләрне сайларга теләүчеләр аз. Укучыларны рухи-әхлакый яктан тәрбияләүдә нәкъ менә филология фәннәре иң әһәмиятлеләреннән санала.

Тәкъдим ителгән электив курс гуманитар профильне, тормышка ашыру максатыннан төзелде. "Сүз – күңел көзгесе" электив курсының эчтәлеге рухи-әхлакый тәрбия бирүнең төп чарасы булган туган тел һәм әдәбият укытуга игътибарны көчәйтүне, балаларны кызыксындырып, аларның филология өлкәсендә белемнәрен тирәнәйтүне эченә ала, укучыларның танып-белү активлыгын үстерүне, тикшеренү-эзләнү эшчәнлегенә өйрәтүне, югары уку йортында кирәк булган интеллектуаль күнекмәләр бирүне күздә тота.

**Курсның төп максатлары**:

- укучыларда туган телебезгә кызыксыну тәрбияләү;
- телдән һәм язма сөйләм культурасы формалаштыру;
- туган телебезнең грамматик, стилистик, орфографик, орфоэпик кагыйдәләрен яхшы үзләштерү һәм тел чараларын уңышлы куллана белергә өйрәтү.

**Курсның бурычлары:**

- төрле жанрдагы текстларны өйрәнү һәм чагыштыру, аларны көндәлек тормышта куллану;
- укучыларның танып-белү һәм логик фикерләү сәләтләрен үстерү;
- мөстәкыйль эшләү күнекмәләре булдыру;
- балаларның иҗади эшчәнлеген оештыру,
- Бердәм республика имтиханнарына әзерләү;
- аралашу культурасы тәрбияләү.

Белем бирүнең актив формалары (материалны үзлектән өйрәнү, семинарлар, диспутлар, иҗади очрашулар уздыру, электрон текстлар белән эшләү, Интернеттан файдалану, төрле жанрдагы иҗади эшләрне яклау, экскурсияләр) укучыларның мөстәкыйль уку эшчәнлеген үстерә һәм электив курсның нәтиҗәлелеген арттыра.

Электив курс программасы 11 нче сыйныф укучылары өчен атнага 1 сәгать исәбеннән дәрес уздыруны күздә тотып төзелде.

**Электив курсның тематик планы,** 11 сыйныф

| № | Тема | Үткәрү формасы, эш төре | Сәг. саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Хәзерге татар әдәби теленең стильләре | Кереш лекция, конспект язу, әңгәмә, төрле стильдәге текстларның аудиоязмаларын тыңлау. | 3 |
| 2 | Текст турында төшенчә. Текст төрләре. Текстның төзелеше | Лекция, гамәли эш, әдәби текстка анализ, сәнгатьле уку | 4 |
| 3 | Матур әдәбият тексты | Лекция, диспут, матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр уку, анализ, иҗади язма эш, татар язучыларының язу стилен карау, чагыштыру. | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Публицистик текст | Лекция, газета-журналлардан күргәзмә оештыру, мәкаләләр уку, “Чистай хәбәрләре” газетасына хәбәр язу (электрон вариантта), типографиягә экскурсия, журналистлар белән очрашу | 5 |
| 5 | Рәсми-эшлекле текст | Лекция, гамәли эш, эшлекле уен: Интернет челтәренә шәхси резюме урнаштыру яки портфолио яклау | 3 |
| 6 | Фәнни текст | Лекция, конспект язу, фәнни текстлар язу алгоритмын эшләү, фәнни эшнең чыгыш ясау өчен кыскартылма текстын әзерләү, семинар, укучыларның чыгышлары | 4 |
| 7 | Текст белән эшләү. | Текстны төзәтү, кыскарту, компьютерда язу, текстларны анализлау. | 8 |
| 8 | Сөйләм культурасын | Диспут. Түгәрәк өстәл уены. Практик дәрес. Доклад белән чыгыш ясау. | 4 |
| | | **Барлыгы:** | **34** |